**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 23 май | № 335

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре диспансеризациясен оештыру турында» 2011 ел, 7 ноябрь, 922 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре диспансеризациясен оештыру турында» 2011 ел, 7 ноябрь, 922 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 5 декабрь, 994 нче; 2012 ел, 11 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 10 декабрь, 964 нче һәм 2014 ел, 29 октябрь, 798 нче, 2016 ел, 30 гыйнвар, 55 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына агымдагы елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасын файдаланып төзелгән, фамилиясен, исемен һәм әтисе исемен, шулай ук биләп торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын күрсәтеп, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар исемлеген Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тапшырырга тәкъдим итәргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков